Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге Советы Карары

22 апрель 2019 ел № 92

Өҗем авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендәге 36 номерлы карары белән расланган Әтнә муниципаль районы «Өҗем авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 30 октябрендәге 382-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, 2018 елның 27 декабрендәге 559-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Өҗем авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең аерым нормаларына Әтнә районы прокуратурасының 2019 елның 24 мартындагы 02-08-02-2019 номерлы протестын карап тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Өҗем авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендәге 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Өҗем авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 11.4 пунктын өстәргә:

«11.4 Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайлау профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен әлеге вазыйфаны биләгән чорда яклый алмый.»;

б)11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 11.5 пунктын өстәргә:

11.5. Гражданин яки муниципаль хезмәткәрнең муниципаль берәмлек территориясендә вәкиллекле орган рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы , суд һәм хокук саклау органнарында туганнары булган очракта (ата-анасы, хатыны, балалары, бертуган, сеңелләре, шулай ук тормыш иптәшенең бертуган, сеңелләре, ата-аналары, балалары, балаларының тормыш иптәшләре), ул муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы Рәисе, Рәисе урынбасары һәм хисап органы аудиторы вазыйфаларына билгеләнә алмый.

в) 12 статьяның 12.1 пунктындагы 3 пунктчасына "сәяси партия " сүзләреннән соң; "муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, шул исәптән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу" сүзләрен өстәргә; "сәяси партиядән тыш" сүзләреннән соң "һәм һөнәри берлек органы, шул исәптән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән" сүзләрен өстәргә.

г)12 статьяның 12.1 пунктындагы 3 пунктчасына "бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл башлыгы А.Т.Валиев